# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2006 елның 5 июлендә кабул ителде

**1 статья**

“Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле бишенче, алтынчы, җиденче һәм сигезенче абзацлар өстәргә:

“Татарстан Республикасы территориясендә ташуларга каршы чаралар әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

кечкенә күләмле йөзмә чараларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау;

суда кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау;

Татарстан Республикасы документациясенең территориаль иминияте фондын булдыру һәм аның турындагы нигезләмәне раслау;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2006 елның 20 июле

№ 58-ТРЗ